**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

11 номерлы 2020 елның 03 ноябре

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 24 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Түбән Баланда авылы, Яшел урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Баланда авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авыл үзара салым яшәүче гражданнар Терешкова, Ленин, Заречная, Жданов урамнарында алып бару мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Түбән Баланда авылы, Яшел урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Баланда авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авыл үзара салым яшәүче гражданнар Толстой, Яшел, Искра, Яңа, Чапаев урамнары алып бару мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләсе расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге Түбән Баланда авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Түбән Баланда авылында урамнарны яктыртуны оештыру тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
- Түбән Баланда авылы территориясенде усентелерне чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү)

**Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

- Түбән Баланда авылындагы тирән насосны ремонтлау, суүткәргечне ремонтлау һәм алыштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

**Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- Контейнер мәйданчыклары төзү (килешү буенча материал сатып алу), Түбән

Баланда авылы контейнерлары сатып алу.

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Вак таш түшәмле юллар төзү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, вак ташны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү Түбән Баланда авылында Яңа урамы, Чапаев урамы, Терешкова урамы, Яшел урамы.
- Кышкы чорда Түбән Баланда авылында автомобиль юлларын карап тоту (урамнарны кардан чистарту, килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы С. С. Елисеев

СОВЕТ КРИВООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ